ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1782**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 февралендәге 256 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы үзәге - Зеленодольск шәһәреннән 11 километр ераграк урнашкан, Зеленодольск муниципаль районы авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәк булган товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы "Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрнең үз көчләрен югалтуын тану турында" карары, 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү хакында»гы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 февралендәге 256 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы үзәге - Зеленодольск шәһәреннән 11 километр ераграк урнашкан, Зеленодольск муниципаль районы авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәк булган товарларны илтүгә бәйле булган, кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында»гы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарга 1 нче кушымтаның 7.1 пунктын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты субсидия алучының субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән аларны билгеләнгән тәртиптә бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, мәҗбүри тикшерү үтәлешен гамәлгә ашыралар.

Муниципаль финанс контроле органы ("ЗМР контроль-хисап палатасы" МУ) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә мәҗбүри тикшерү үткәрә»;

1.2 Карарга 1 нче кушымтаның 7.3 пунктын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Субсидияләр биргәндә, аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр алучыларның ризалыгы субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүләр, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук муниципаль финанс контроле органы тарафыннан («ЗМР контроль-хисап палатасы» МУ) тикшерүләр гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән ризалык, ризалыгы турында әлеге шартны үз эченә алган субсидия бирү турындагы килешүгә кул кую белән чагылдырыла».

1.3. Карарга 2 нче кушымтаның 6.3 пунктын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Әлеге шартнамәгә кул кую белән субсидия алучы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә, субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук муниципаль финанс контроле органы («ЗМР Контроль-хисап палатасы» МУ) тарафыннан тикшерүләрнең үтәлешенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыруга үзенең ризалыгын белдерә.»;

1.4. «Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составы» карарының 2 нче кушымтасына Комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлегенең баш белгече Р.Г. Сәлахованы комиссия составыннан чыгарырга,

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлегенең баш белгече Л.Ю. Гыйләҗиеваны комиссия составына кертергә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек белән ММЧ элемтә буенча бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Бауэрга йөкләргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе И. Р. Ганиев